ӘТИЛЕ-УЛЛЫ ИДРИСОВЛАР:
«Без башка тормышны белмибез!»
> 2

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК...
Укучыларыбызның уй-фикерләре, истәлек-хатирәләре
> 3

МӨБАРӘК БУЛСЫН!
Себердән алып Ленинградка кадәр милли бәйрәм – Сабан туе гөрләде
> 4

КАДЕРЛЕ ЧАКРЫМНАР
«Ефәк юлы – 2023» узышында 10 көндә 5241,27 чакрым юл үтәчәкләр
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 93 (29060) | Сишәмбе | 4 июль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эльвира ВӘЛИЕВА

ЫШАНМА СҮЗЕНӘ...

Яшәеш

Тикшеренүдән күренгәнчә, илдә яшәүчеләрнең 94 процентына телефон мошенниклары шалтыраткан яки смс-хәбәр юллаган. Татарстан халкы кырыгалдарларга атна саен уртача 20 миллион сум акча күчерә. Бу хәлләргә Роскомнадзор чик куймакчы. Кәрәзле элемтә операторлары якын арада ук усал ният белән шалтыратучыларны үзеннән-үзе өзүче «акыллы» системага күчеп бетәчәк, дип көтелә. Алданудан туктарбызмы?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Югары Осланда яшәүче Рәсимә Гайнетдинова алдакчылар кармагына эләккәнен үзе дә сизми калган.

– Кырыгалдарлар турында гел сөйләп торалар. Тик алдану бик тиз икән. Үзен банк хезмәткәре дип таныштырган ир-ат телефон аша: «Сезнең исемгә кредит рәсмиләштергәннәр. Аны ябу өчен, тиз арада арадашчы-курьерга 400 мең сум акча тапшырырга кирәк. Соңрак барлык сумма бербөтен булып кире кайтачак», – дип өзми-куймый сөйли башлагач, әллә нишләп киттем. «Хәзер үк банктан кредит рәсмиләштермәсәгез, тагын да зуррак суммага бурычка батачаксыз», – дип тә куркыттылар. Бер сәгать эчендә биш тапкыр шалтыраткач, өйдән ничек җыенып чыгып киткәнемне, якындагы банк бүлекчәсенә барып җиткәнемне дә хәтерләмим. Шөкер, банк хезмәткәрләре туктатып калды. Югыйсә урамда акчаны көтеп торалар иде инде, – дип сөйли пенсия яшендәге ханым.

Татарстанда яшәүчеләр арасында мондый мисаллар бихисап. Республика буенча Эчке эшләр министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, былтыр Татарстан халкы телефон һәм интернет мошенникларына 3 миллиард сумга якын акчасын күчергән. Республика әле дә – онлайн рәвештә алданулар иң күп теркәлгән төбәкләр исемлегендә. Татарстанда яшәүчеләр дистанцион эш итүче кырыгалдарларга атна саен уртача 20 миллион сум акча күчерә. Мошенниклар үзләре генә дә эш итми. Хокук саклаучылар аларның арадашчыларын да җавапка тарта. Шушы көннәрдә генә Татарстанда яшәүче 19 һәм 20 яшьлек ике егетне, пенсионерларны алдаучыларга ярдәм итеп ятканнары өчен, шартлы рәвештә 2,5 елга ирекләреннән мәхрүм иттеләр.

«TelecomDaily» мәгълүмат-аналитика агентлыгы үткәргән тикшерүдән күренгәнчә, илдә яшәүчеләрнең 94 процентының кырыгалдарлар белән аралашканы яки алардан смс-хәбәрләр кабул иткәне бар. Алай гына да түгел, илдә яшәүче һәр ике кешенең берсенә телефон мошенниклары айга ике һәм аннан да күбрәк тапкыр шалтырата.

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының матбугат үзәгеннән хәбәр итүләренчә, быел беренче өч айда гына да республикада яшәүчеләрнең банк карталары һәм хисап счетларыннан 2,5 мең тапкыр акча урлау очрагы теркәлгән. Алар буенча судка 500дән артык җинаять эше җибәрелгән. Гаепләнүчеләр исемлегендә 400ләп кеше бар.

– Татарстанда кылынган барлык җинаятьләрнең дүрттән бер өлеше банк карталарыннан акча урлау һәм мәгълүмат технологияләрен кулланып, халыкны төп башына утыртуга бәйле, – ди Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының Җинаятьчеләрне эзләү идарәсе җитәкчесе урынбасары Рәмис Газимов. – Хокук саклаучылар мондый җинаятьләр буенча республикада яшәүчеләрдән көн саен якынча 30–35 гариза кабул итә. Татарстан халкы читтән торып эш итүче кырыгалдарларга атна саен уртача 20 миллион сум акча күчерә.

Күңелне юатыр өчен булса да әйтик: Татарстан әлеге төр җинаятьләрнең эзенә төшү буенча Идел буе федераль округында – беренче, ә мошенникларны тотмарлау ягыннан – Мәскәүдән кала, ил буенча икенче урында. Тик алданучылар булганда, эш тә кимемәячәк шул. Вазгыять якын арада үзгәрмәгәе. Тиздән кәрәзле телефон операторлары усал ният белән таныш түгел номердан шалтыратучыларга чик куючы «акыллы» системага күчеп бетәргә тиеш. Бу хакта Роскомнадзор хәбәр иткән. Әйдәп баручы дүрт компания бу системага кушылган да инде. Әйтүләренә караганда, инде хәзер үк көненә 2,5 миллионлап ялган шалтыратуны өзәләр. «Калган кәрәзле элемтә операторларына исә киләсе елның язына кадәр вакыт биреләчәк», – дигәннәр Роскомнадзорда.

Психолог Венера Касыймова фикеренчә, «Алданудан кайчан туктыйбыз?» дигән сорауга төгәл җавап юк.

– Халыкны гына беркатлылыкта гаепләргә ярамый. Үзебез үк күреп торабыз: телефон мошенниклары гади генә алдакчылар түгел. Алар психологлар кебек бик оста эш итә. Миңа калса, хәзер бу эш белән аерым кешеләр генә түгел, ә махсус төркемнәр шөгыльләнә. Аларны халыкны төп башына утыртырга махсус әзерләүләренә дә шикләнмим. Бу – җиңел юл белән керә торган акча. Шуңа күрә безне алдарга тырышучылар бетмәячәк. Аларның алымнары гына үзгәрәчәк. Таныш түгел номердан нинди сәбәп белән шалтыратуларын ачыклауга, телефонны өзеп куярга кирәк. Югыйсә хәзер кайберәүләр, үзләрен акыллы хис итеп, мошенниклар белән сүз куертырга тотына. Исегездә тотыгыз: уеннан уймак чыгарга да мөмкин, – ди белгеч.

ЧИТ НОМЕРЛАРДАН ШАЛТЫРАТЫП,
(кирәкмәгән смс-хәбәрләрне дә кертеп)
ЕШ БОРЧЫЙЛАРМЫ?
(процентларда)



- Елга берничә тапкыр → 35,8
- Айга берничә тапкыр → 32,6
- Бик сирәк → 13,1
- Атнага берничә тапкыр → 11,9
- Бик еш → 6,6

«TelecomDaily» мәгълүмат-аналитика агентлыгыннан

Ташлама каралган

Быел Украинадагы хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның балалары, шулай ук Россия Геройлары һәм Батырлык орденнары белән бүләкләнүчеләр югары уку йортларына ташламалы шартларда керергә хокуклы. Бу хакта Россия вице-премьеры Дмитрий Чернышенко хәбәр итте.

Чернышенко билгеләп үткәнчә, хөкүмәт йөкләмәсе нигезендә, абитуриентлар өчен барлыгы 626 мең бюджет урыны бүлеп бирелгән, шул исәптән Луганск, Донецк Халык республикалары, Херсон һәм Запорожье өлкәләре югары уку йортлары өчен 36 меңнән артык урын каралган. «Быел, узган ел белән чагыштырганда, бюджет урыннары саны ил икътисады өчен өстенлекле һөнәрләргә, бигрәк тә инженерлык белгечлекләренә якынча 2 меңгә артты. Андый һөнәрләргә 12 меңнән артык урын бүлеп бирелде», – диде ул.

Ул искәрткәнчә, хәзерге вакытта гариза тапшырган абитуриентларның саны 260 меңнән артык. Кабул итү кампаниясе башланганнан бирле алар 660 меңләп гариза тапшырган. Алдынгы төбәкләр арасында – Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Татарстан.

Россия вице-премьеры искә төшергәнчә, агымдагы елда абитуриентлар өчен махсус онлайн хезмәт эшли («Поступление в вуз онлайн»). Әлеге портал аша 1 меңнән артык уку йортына гариза биреп була. Документларны тиз тикшерәләр, уку йортына да барып йөрисе юк.

Унтугызынчы

Татарстан юл сыйфаты буенча төбәкләр рейтингында унтугызынчы урынга чыккан. Исемлекне узган ел йомгаклары буенча «РИА Новости» агентлыгы төзегән.

Республикада нормативта каралган таләпләргә җавап бирүче автомобиль юлларының өлеше 64,4% тәшкил итә. Шул ук вакытта каты түшәмәле юллар өлеше – 1 мең кв. километр мәйданга 471,4 чакрым.

Рейтингта безнең күршеләр – Чукотка автономияле округы (65,4%) һәм Красноярск крае (63,2%). Алар 18 һәм 20 нче урыннарга чыккан. Мәскәү, гадәттәгечә, беренче урынны алган: башкала юлларының 97,6 проценты тиешле таләпләргә туры килә. Шулай ук Ханты-Манси автономияле округы – Югра, Красноярск крае, Чиләбе өлкәсе һәм Ингушетия дә лидерлар сафына кергән.

Ә инде иң начар юллар – Архангельск өлкәсендә: биредә аларның 13,3 проценты гына норматив күрсәткечләргә туры килә. Киров өлкәсе (25%) һәм Марий Элда (27,7%) да хәлләр әллә ни мактанырлык түгел.

Табышлы төбәк

Быел апрель аенда Татарстанда яшәүчеләрнең уртача хезмәт хакы Идел буе федераль округында иң күләмлесе булып чыккан. Росстат мәгълүматлары буенча, ул 58907 сум тәшкил иткән. Эш хакының уртача күләме 50 мең сумнан күбрәк булган округ төбәкләре исемлегенә шулай ук Пермь крае, Башкортстан, Удмуртия республикалары, Түбән Новгород, Оренбург һәм Самара өлкәләре кергән.

Ә менә Марий Эл һәм Мордовия республикалары рейтингта иң соңгы урыннарны алган. Бу төбәкләрдә яшәүчеләр аена уртача 45 мең сумнан кимрәк акча алып эшли.

Төзек булса, күңелле

Татарстанда күпфатирлы йортларны капиталь төзекләндерү 69 процентка төгәлләнгән. Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары Алексей Фролов әйтүенчә, 134 йортта эшләр тулысынча тәмамланган. 588ен төзекләндерү дәвам итә.

Бер ай эчендә барлыгы 74 йортта капиталь ремонтны төгәллләгәннәр. Бер ай элегрәк төзекләндерү эшләре 662 объектта алып барылган.

Быел күпфатирлы йортларны капиталь төзекләндерү программасында өч район – Әлки, Кайбыч һәм Чирмешән районнары катнашмый. Бу акча җитмәүгә бәйле.

Көн кадагында

Кыздыру бәясе

Бу атнадан Татарстанда корылык аркасында гадәттән тыш хәл режимы кертергә җыеналар. Ник дигәндә, республиканың күпчелек районнарында һавада гына түгел, туфракта да корылык күзәтелә. Бу хакта журналистлар белән очрашуда Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров хәбәр итте.

«Татар-информ» / С.Камалетдинов

Министр сүзләренә караганда, июнь аенда Татарстанда нибары 15 миллиметр явым-төшем булган. Норма буенча бу айда уртача 60 миллиметр яңгыр яварга тиеш икән.

– Быел һава торышы безне һәркөн шаккатырып тора. Яз да иртә килде, чәчүдән соң көннәр суытты, уҗымнар тишелеп чыккач, салкыннар кабатланды. 50 мең гектар чамасы культураларны яңадан чәчәргә туры килде. Яңгыр яумау бөртекле культураларның уңышына бик нык тискәре йогынты ясый, – ди Марат Җәббаров. – Гадәттән тыш хәл режимы кертелүдән уҗымнарны иминиятләштергән хуҗалыклар отачак. Быел андый хуҗалыклар саны узган ел белән чагыштырганда күбрәк.

Быел республикада 3,7–3,8 миллион тонна уңыш җыеп алырга планлаштыралар. Министр сүзләренә караганда, республикада терлек азыгына да кытлык булырга охшап тора. Җитмәгәнен күрше төбәкләрдән сатып алырга җыеналар. Бу уңайдан сөйләшүләр башланган инде.

Синоптиклар да, яңгырлар тиз генә яумас әле, ди. КФУның метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы доценты Тимур Әүхәдиев сүзләренә караганда, быел Татарстанда май белән июнь айларында уртача һава температурасы 16 градус тәшкил иткән.

– Язның соңгы ае өчен югары саналса да, июнь өчен бик аз бу. Норма буенча июньдә уртача һава температурасы, ким дигәндә, 18,5 градус булырга тиеш. Июньнең икенче яртысында төшкән кырау да шаккатырды. Соңгы тапкыр июнь аенда мондый түбән температура 2017 елда теркәлгән иде. Ул чакта җәйнең беренче аенда 15,6 градус җылы булган, – ди белгеч.

Татарстан буенча Гидрометеорология үзәге мәгълүматларына караганда, июль аенда чын җәй күтәлә. Һаваның уртача айлык температурасы нормадан бер градуска югарырак булачак. Июльнең беренче яртысында республикада уртача 20 градус җылы булачак. Ә менә яңгырлар бик көттереп кенә явачак, дип фаразлый синоптиклар.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Элла ПАМФИЛОВА, Россия Үзәк сайлау комиссиясе башлыгы:

Киләсе елда булачак Президент сайлау – чираттагы, гадәти генә сайлау түгел. Ул алдагы күп елларга Россиянең генә түгел, бөтен дөньяның язмышын билгеләячәк.

(«Российская газета»дан)

ТАТАРСТАНДА – АКЧА ТОТУ

2023 елның гыйнвар – март айларында банк картасы белән 237 миллион мәртәбә акча түләгәннәр. Бу – узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 11 процентка күбрәк.

БАНК КАРТАСЫ БЕЛӘН ТҮЛӘНГӘН
гомуми акча >> **179,6 млрд сум**
бер түләү (уртача) >> **758 сум**
бер мәртәбә картадан акча алу (уртача) >> **17,7 мең сум**

Татарстанда яшәүчеләрнең **11,5 мең** түләү картасы бар
һәр кешедә – **3 карта** (уртача)
104,4 мең электрон терминал



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КАРА ТӘНЛЕ ФЕТНӘ

Дөньякүләм киеренкелек атнадан-атнага югарыгарак омтыла. Зур сәясәтчеләр хәзер бөтендөнья сугышын котылгысыз нәрсә буларак телгә алалар. Төп максат базарларны яңадан бүлү булса да, халыкларга бөтенләй башка идеяләр тәкъдим ителә. Планетада нинди генә киеренке вакыйга тумасын, аның артында, нигездә, зур гөрелте кебек көчәюче финанс кризисы ята. Швециядә Коръән яндыралар икән, моны ислам дөньясын кабызып җибәрү һәм Якын Көнчыгышта зур сугышка җирлек әзерләү өчен эшлиләр. Нәтиҗәсе озак көттерми. Багдадта гыйраклылар швед илчелеген штурмладылар, илчелек хезмәткәрләре кайсы кая качып бетте. Җиддәдә кемнәрдер АКШ консуллыгына атты. Фәләстыйн – Израиль конфликты яңа югарылыкка күтәрелергә әзерләнә. Киеренкелек шартлау ноктасына җиткәнче тырышачаклар – монысына шик юк.

Соңгы көннәрдә Франциядә куәт алган урам протесты – глобаль капитализмның үзе чәчкән орлыклар җимешен татый башлавының җанлы мисалы. Бу юлы француз шәһәрләре пенсия яше күтәрелү уңаеннан да, социаль яклау чаралары таләп итеп тә түгел, ә милли һәм расачылык идеяләрен байрак итеп күтәреп, фетнә учагына әверелде. Сценарий АКШта Трамп Президентлыгы вакытында башланган Black Lives Matter (кара тәнлеләр тормышы әһәмияткә ия) дип аталган гыйсъянчылык хәрәкәте ысулы белән тормышка ашырыла. 27 июнь көнне ике полицейский Наэль исемле 17 яшьлек үсмерне «Мерседес» автомобилендә барганда юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен туктата. Полиция белән очрашу бу юлы егет өчен һәлакәткә әйләнә: ул атып үтерелә. Вакыйганың нечкәлекләренә без тукталып тормыйбыз. Аның илкүләм гыйсъянчылык хәрәкәтенә ут кабызып җибәрүче чакматаш ролен уйнавын гына искәртәбез. Асылда үткән гасырда французлар алып барган колониаль сәясәт һәм Алжирда алар кылган вәхшилекләр шулай кайтаваз бирә. Хәер, яңа гасырда да Париж Африкада астыртын ерткычлык сәясәтен алып баруын туктатмады. Бүгенге Франциянең үзендә дә алдагы буыннары мөһаҗирләр булган гражданнарның ирекләрен кысу һәм аларны түбәнсетү киң җәелде. Шулар барысы бергә зур шартлау тудырды инде. Протест шулкадәр көчле башланып китте һәм дәвам итә: Президент Макрон, Брюссельдәге Евросоюз саммитын ташлап, илгә кайтты һәм чит илләргә барлык визитларын туктатты. Фетнәчеләрнең, полиция участокларына һөҗүм итеп, кулларына корал алу фактлары шактый. 1 июль киченә вазгыять шундый иде: икътисад һәм финанслар министры Брюно Ле Мэр әйтүенчә, илдә 250 банк, 200 кибет, 10 сәүдә үзәге таланган. Массакүләм кулга алулар фетнә температурасын төшерүгә аз булышты. Макрон фетнәдә социаль челтәрләрне гаепләде. Франция Компартиясе җитәкчесе Фабьен Руссель дә тәртипсезлекләр вакытында социаль челтәрләрне өзеп торырга чакырды. Кыскасы, фетнәгә каршы көрәштә Европа демократияләре Кытайдан яисә Россиядән аз аерылалар. Төп сәбәпнең лидерлар алып барган сәясәттә булуын берәүнең дә таныйсы килми. Әйтик, Франциянең дәүләт әҗәте 3 триллион евроны узып китте. Социаль киеренкелекнең этәргеч сәбәпләре интернетта түгел икәнен аңларга шул бер факт кына да җитә.

Россиядә

КАЗНАНЫ ТУТЫРГАН ДЕВАЛЬВАЦИЯ

Дөньякүләм икътисад кризисы Россиядә дә чагылыш таба. Бездә ул санкцияләр фонында бара. Путинның йөрәккә май булып ятучы чыгышларын тыңлап, аягүрә матур төшләр күреп яшәргә була, әлбәттә. Әмма картага керүгә эссе көндә җебегән туңдырма кебек эреп бетүче хезмәт хаклары барыбер сискәнеп уяныргa мәҗбүр итә. Пригожин фетнәсе сум курсын ярдан түбән этеп төшерде. Доллар белән евро берсен берсе узышып кыйммәтләнә башладылар. Бер доллар 86 сум 14 тиен йөри башлагач, телеграм-каналлар исәпләп күрсәтте: бер ел эчендә сумның девальвациясе 65 процентка җиткән икән. Әйе-әйе, бу юлларның авторы үткән көздә генә 60 сумнан йөргән долларны хәтерли. Хәзер финанс белгечләре июльдә доллар 90 сумнан югарырак йөрер дип фаразлый. 89 сумда ныгып маташты бит инде үткән атна ахырында ук. Шатланырга теләгән кеше шатлансын, кайгырасы килгәннәр кайгырсыннар: ит белән сөттән кала барлык товарлар да кыйммәтләнәчәк. Импорт товарлар да, үзебездә җитештерелгәннәре дә бәягә бәя өстәр. Соңгылары да бит аның импорт комлектлаучы детальләрдән тора.

Аз керемле кулланучылар өчен фаҗигагә якынайган бу факт казна өчен бер дә начар түгел. Газета хәбәрчесе үз калькуляторын кушып азапланмады, чөнки телеграм-каналлар тизрәк исәпли. Долларның хәзерге маршы бюджетка 4 триллион сумга якын акча бирде, диләр. Америка кәгазенең бәясен 100 сумга кадәр җиткерсәң, тагын 2,5 триллион сум савып булачак икән. Аңларга кирәк: акчаны безнең кесәләрдән суырачаклар. Турыдан-туры булмагач, бәяләрнең традицион күтәрелеше дип кенә аңлаячакбыз. Качып кына, Минфин безнең кесәгә керә дип беркем дә әйтмәячәк. Ат йөреше ясап, статистика илдә эчке тулай продуктның көчле үсешен күрсәтәчәк. Алдамаячак. Чагыштыру өчен саннарны ничек итеп алуга бәйле рәвештә, уңышларны күп санарга мөмкин. 2022 елның мае белән чагыштырсаң, 5 проценттан арткан үсеш темплары күрәчәксең. 2021 ел маен нигез итеп алсаң, үсеш юк диярлек. «Россиядә бары тик бәяләр генә үсә» дигән кагыйдә үз көчендә бик озакка калыр, мөгаен. Аннан чыгармалар да булгалар, билгеле. Беренчел торак базарында бәяләрнең черки күзенә кырып салырлык күләмдә генә кимүе турында хәбәрләр бар, мәсәлән.

Икътисад фронтында кыенлыклар туып кына тора. Кытай белән сәүдә итүне авырайта торган бер мәсьәлә көн тәртибенә басып маташа. Россиянең тимер юл станцияләре буш контейнерлар белән тулган, чөнки кытай товарларын шуларга тутырып китерәләр, Россия чималы бөтенләй башка ысул белән ташыла. Нәтиҗәдә Кытайга буш контейнерлар ташырга туры килә. Бу – оттырышлы ысул. Вазгыять бик катлаулы, ди транспорт компанияләренең менеджерлары.

ИСКЕСЕЗ ЯҢА БУЛМАС

Рәис көндәлеге

Казанда «РЕБУС» чишәләр. Татарстан башкаласында әнә шул исемдәге ике көнлек халыкара форум уза. Аны үткәрү урыны итеп нәкъ менә Казанны сайлаулары очраклы түгел.

tatarstan.ru

«РЕБУС» форумы Татарстанда тәүге тапкыр үткәрелә. Җыенның исеме рус телендәге «реновация», «единство», «баланс», «устойчивость» һәм «строительство» сүзләренең беренче хәрефләреннән ясалган. Быел ул шәһәрләрнең тарихи үзәкләрен саклап калу һәм үстерүгә багышланган. Форумның оештыру комитеты мәгълүматларына караганда, чарага 15 чит илдән, илнең 50 төбәгеннән 2 мең кеше чакырылган.

Форумның пленар утырышында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Җыен кунакларын сәламләгәндә ул тарихи шәһәрләрдә төзелеш алып баруның әһәмияте турында да әйтте.

– Дәүләт һәм шәхси бизнес заманча объектлар төзелешенә күп көч сарыф итә. Тарихи үзәкләрдә дә төзиләр. Биредә алтын урталыкны саклап калу мөһим: бер яктан, яңа биналар биредәге архитектурага яраклашып, шәһәр халкына файда китерсә, икенчедән, ул икътисадый яктан да үзен акларга тиеш. Сүз дә юк, шәһәр үзәгенә инвестицияләр озак вакытка исәпләнгән, – диде Рәис.

Аның әйтүенчә, тарихи территорияләрдә үсеш өчен зур мөмкинлекләр бар. Шуңа күрә дә әлеге юнәлештә эшләргә кирәк, дигән фикер җиткерде Рөстәм Миңнеханов.

– Бу – Татарстанның дәүләт мәдәни сәясәтенең өстенлекле юнәлешләреннән берсе, – диде ул. – Республикада 3 Бөтендөнья мәдәни мирас объекты, төбәк дәрәҗәсендәге – 11 һәм федераль дәрәҗәдәге 2 тарихи җирлек бар. Татарстанда 1139 мәдәни мирас объекты саклана.

Әлеге эшнең нәтиҗәсе дә күз алдында. Рөстәм Миңнеханов Казан, Болгар кебек тарихи шәһәрләрне үстерүнең отышлы яклары турында әйтте. Тарихи һәйкәлләрне яңарту, иҗтимагый киңлекләрне төзекләндерү нәтиҗәсендә республикага килүче туристлар саны елдан-ел арта. Татарстанда елына 4 миллионга якын турист кунак була. Алар буш кул белән килми, әлбәттә.

Рөстәм Миңнеханов республикада тарихи шәһәрләрне үстерү мәсьәләләрен җайга салу өлкәсендә шактый эш башкарылуын да искәртте.

– Барысын да дөрес итеп оештырсаң, әлеге җирлекләр инвесторларга да кызыклы булачак. Без моңа тиз генә килмәдек, әлбәттә. Үзебезгә белгечләр чакырдык, кирәкле компетенцияләр булдырдык. Ялгышлар да булды. Ничек кенә булмасын, без алга атларга мөмкинлек бирүче мохит барлыкка китердек, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Форумда катнашучыларны видеоэлемтә аша Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин да сәламләде.

– Без үзенчәлекле тарихи архитектура һәйкәлләрен ничек бар шулай саклап калырга тырышырга, әлеге мирасны гомуми шәһәр мохитенә яраклаштырырга тиеш. Форумны үткәрү урыны итеп Казан очраклы гына сайланмады. Татарстан башкаласы шәһәр үзәген үстерүдә бай тәҗрибәгә ия, – диде Марат Хөснуллин.

Җыенның әһәмиятен Казанга килгән Ханчжоу шәһәре (Кытай) мэры урынбасары Сан Сюдонг та билгеләп үтте. Аның фикеренчә, Казан һәм Ханчжоу шәһәрләренең бай тарихи һәм мәдәни мирасы бар.

Форум кысасында Рөстәм Миңнеханов Россия Дәүләт Думасының төзелеш һәм ТКХ комитеты җитәкчесе Сергей Пахомов белән дә очрашты. Яклар төзелеш тармагын үстерү, төзелешкә комачаулык итүче административ киртәләрне киметү, күпкатлы йортлар белән идарә итү системасын камилләштерү, ТКХ инфраструктурасын яңарту турында фикер алышты.

Үзебезне күрсәтү

Очрашу

Иң каттә сыерлар, виртуоз һәм иң оста тракторчылар, агросәнәгать комплексындагы казанышлар. 6–9 июльдә Татарстанда узачак «Бөтенроссия кыр көне – 2023» күргәзмәсе әнә шундый кызыклы чараларга бай булачак.

– Бөтенроссия кыр көне ел саен Россиянең төрле төбәкләрендә уза. Татарстанда әлеге чара 2017 елда уздырылган иде. Һәм безне шундый зур вакыйга үткәрү мәйданы буларак икенче тапкыр сайлаулары – бик зур дәрәҗә. Бу безнең төбәкнең потенциалын бөтен Россиягә күрсәтү, партнерлар һәм инвестицияләр җәлеп итү өчен мөмкинлек бирә, – диде матбугат очрашуында республиканың авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров.

Кыр көне кысасында зур чаралар да планлаштырылган. Әйтик, сөрү буенча X ачык Россия чемпионаты узачак. Монда Россиянең 40 төбәгеннән һәм Белоруссия, Кыргызстан, Казахстаннан килгән 65 иң яхшы механизаторга кыска вакыт эчендә катлаулы участокны эшкәртеп чыгарга туры киләчәк. Чемпионатта Татарстан данын сигез кеше яклаячак. Аларның икесе – кызлар.

Бөтенроссия кыр көне – саннарда

- ✓ Күргәзмә **40** гектар мәйданны алып торачак.
- ✓ Чарага **50** төбәктән кунаклар килүе көтелә.
- ✓ Анда **250**дән артык компания **300**дән артык авыл хуҗалыгы техникасын тәкъдим итәчәк. Шулай ук селекция, агрохимия һәм үсемлекләрне саклау өлкәсендәге казанышлар белән танышырга мөмкин булачак.
- ✓ Сортларны сынау участогында Россиядә җитештерелгән **280** ашлык, техник һәм май культураларының үрнәкләре тәкъдим ителәчәк.
- ✓ «Казан Экспо» үзәгендә **25** эшлекле чара узачак.

Моннан тыш, чемпионатта катнашучылар «Трактор-шоу» ярышында беренче тапкыр Кытай тракторларында (ZOOMLION) үз осталыкларын күрсәтә алачак.

Сөт юнәлешендәге терлекләрне билгеләү буенча Бөтенроссия конкурсы да шушы көннәрдә узачак. Әйтергә кирәк, ил дәрәҗәсендә мондый чара беренче тапкыр уздырыла. Министр әйтүенчә, бәйгедә 52 хуҗалыктан токымлы 80 сыер катнашачак. Иң күп сөт бирә торган сыерларны Мордовия, Чувашия, Удмуртия республикалары, Ульян өлкәсе һәм Татарстаннан сайлап алачаклар. Монда сыерларның тышкы кыяфәтләре, гәүдә төзелеше, атлап йөрешләре, тояклары, темпераментларына кадәр мөһим роль уйный.

– Мондый конкурс АГРОВОЛГА мәйданында ике тапкыр үткәрелгән иде инде. Ләкин ул вакытта бары тик төбәк форматында гына узды. Хәзер без аны федераль дәрәҗәгә чыгармакчы булабыз. Татарстанның сөтчелек буенча лидер төбәк булуын искә алып, бу бәйгенең бездә уздырылуы бик урынлы, – диде Марат Җәббаров.

Шунысын да билгеләп узарга кирәк: оештыручылар әлеге чараларның аграрийларга гына түгел, барлык халыкка да кызыклы булачагын ышандыра. Балалар һәм өлкәннәр өчен күңел ачу программасы каралган.

Әлеге чараны килеп күрергә теләге булганнар өчен Камал театры, Җиңү проспектыннан бушлай шаттллар йөриячәк. Шулай ук «Казан Экспо»га тимер юл вокзалыннан аэроэкспресста да барып җитәргә мөмкин.

Кыздыру бәясе

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Быел августта һава торышы климатик нормадан артмас дип фаразлыйбыз. Җәйнең соңгы аенда, гадәттә, 18,3 градус җылы була, 54 мм яңгыр яварга тиеш, – ди белгеч.

Балтач районы Янгул авылында яшәүче «халык синоптигы» Әмир Шәрәфиевнең июньгә ясалган фаразлары өлешчә рас килде. Хәтерләсәгез, җәйнең беренче аенда көннәр салкынча булырга тиеш, дигән иде ул. Шулай булды да.

– Июньнең соңгы бер-ике көнендә генә эссе булды. Ай башында явым-төшемнәр күбрәк булыр дип көткән идем. Ләкин ул әллә ни шатландырмады. Дөрес, сирәкмирәк яуса да, үсемлекләрне саклап калырга ярдәм итте ул. Аннары узган ел көзен явым-төшем күп булды. Җир кышка дымлы булып керергә өлгерде. Шуңа күрә бәрәңге тишелгән чорда җирдә дым бар иде әле. Аннары быел туң тирән иде. Ул да дымны саклый. Ә менә кар суыннан әллә ни файда булмады быел. Мартта яуган яңгырлар аларны бик тиз эретеп бетерде, – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

«Халык синоптигы» күптән көтелгән яңгырлар июльдә явачак дип фаразлый.

– Быел урып-җыю иртә башланачак. Игеннәр гадәттәгедән тизрәк өлгерде. Июнь коры булгач, тишелеп чыккан сабан культуралары үсә алмады, башакланырга мәҗбүр булды. Урып-җыюга тотынгач, июльнең икенче яртысында яңгырлар явар әле ул. Көннәр кызу булачак. Ләкин июльдә аномаль эсселәр булса да куркыныч түгел. Ник дигәндә, төнлә чык төшә. Көннәр кыскаргач, җир салкынаеп өлгерә. Шуңа күрә үсемлекләр өчен зыянлы түгел ул, – ди Әмир Шәрәфиев. – Соңгы арада җәй көзгә авышып бара. Соңгы ике елда шул хәл күзәтелә. Быел да искәрмә булмаячак. Сентябрьдә дә җәй дәвам итәчәк. «Әбиләр чуагы» алып килүче алтын көз исә соңарачак.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Июль аена халык сынамышлары

- ■ Июльдә билчән күп икән – суык кыш көтегез. Кузгалак күп булса, кыш җылы килер.
- ■ Кич һава җылынып китсә, яңгыр көт.
- ■ 13 июльдә күке кычкыруын дәвам итсә, җәй матур һәм озак килә, кар соң төшә. Бу көннән соң күке тавышы тынса, кыш иртә килер.
- ■ Егерме бишендә кырау булса, кыш суык килә.
- ■ Июльнең икенче яртысында каен яфраклары агачның очыннан саргая башлый икән – иртә көзгә. Астан өскә таба саргая башласа, көз озак килер.
- ■ Июльнең соңгы көнендә көн эссе булса, декабрь суык килер.

Актаныш

Иске Теләкәй авылында гомер итүче Идрисовлар династиясенең гомуми эш стажы якынча 130 елга тула. Әтиләре Риф абый гомер буе тракторда эшләгән, уллары Нияз белән Рәвис тә әтиләре юлыннан киткән, аларның балалары Рияз, Риназ, Нәфис тә механизатор һөнәрен үзләштергән. Без аларны кызу эш вакытында кайсын – кырда, кайсын сенаж салу базында очраттык.

Зөлфия Хәлиуллина

ҖИР ИСЕ

«Башка тормышны белмим»

Безне алдан ук: «Нинди генә эш кушсак та, батырып эшлиләр. Бервакытта да «юк» дип әйткәннәрен хәтерләмибез. Ә менә сүзгә саран, үзләре турында сөйләргә бер дә яратмыйлар», – дип кисәттеләр. Чын хезмәт кешесенә хас булган иң төп сыйфатларның берсе әнә шул инде. Без килгәндә Рәвис абый җир эшкәртә иде. 25 елдан артык стажы булган механизатор үзе турында ялындырып кына сөйләсә дә, җир темасына күчкәч, күзләре ялтырый ук башлады.

– Аның исләренә кадәр тәмле бит, бөтен нәрсәдән аерылып тора. Эшкәрткән вакытта аеруча хуш ис тарала. Ничек яратмаска мөмкин аны?! Тик быел җир дымга тилмерә. Авыр ел булырга охшап тора. Яз ике атнага иртәрәк килде. Төп чәчү 27 апрельгә беткән иде инде. Башка елларны бу вакытта кырга чыга гына идек әле. Күп урында игеннәрне кырау сукты. Аларны кабат чәчәргә туры килде. Яңгыр бездә күз яше кадәр дә яумады, шунлыктан игеннәр дә үсеп китә алмады. Бик борчылабыз. Көн-төн яңгыр телибез, – диде ул.

Абыйсы Нияз белән кечкенәдән бирле әтиләре тирәсендә кайнашып үскән алар.

– Мәктәптән чыгуга кырга әти янына йөгерә идек. Шундый рәхәт вакытлар иде ул. Аннан соң яныма улларым утырды. Икесе дә чәчү вакытында ярдәмчеләрем булды. Техникумны бетергәч, башта олысы кайтты. Менә бүген кечкенә улым, трактор йөртү таныклыгын алып, беренче көн эшкә чыкты. Аларга бервакытта да: «Улым, син авылда калырга тиеш», – дип әйткәнем булмады. Алар бу юлны үзләре сайлады. Киңәшләшмичә, ярдәмләшмичә эшләп булмый. Белмәгәнне абый белән без әтидән сорадык, улларым миннән сорый.

Рәвис Идрисовның абыйсы – Татарстанның атказанган механизаторы Нияз абыйның эш стажы тагын да күбрәк. Инде 41 ел тир түгә ул.

– Авылдан китәргә кирәк, дигән уйның башыма кереп тә караганы булмады. Мин башка тормышны белмим дә. Яшьтән үк әти белән тракторда үскән малайлар инде без. Эшемне белеп, яратып эшлим. Җир сыйфатлы эшләүне ярата. Шуңа күрә яхшылап эшкәртәбез, тукландырабыз. Улым да йөземә кызыллык китерми. Беркая да китмим, диде, – ди Нияз Идрисов.

Шул ук вакытта ул хуҗалыкка механизаторлар җитмәвен дә, авылның киләчәге өчен борчылуын да әйтте.

– Шушында үстек, шушында яшәдек, эшләдек, балалар үстердек. Эшләп торсак та, яхшы гына яшәсәк тә, авылның киләчәге барыбер борчый. Ул күзгә күренеп сүнә. Яшьләрнең булмавы аяныч. Эшләргә кеше таба алмыйлар, тракторлар буш тора. Хезмәт хаклары да начар түгел югыйсә. Сезонында тагын да яхшы була. Тормыш итәргә җитә, зарланмыйбыз. Кайда да эшләп ашарга кирәк инде, – диде ул.

«Таң» хуҗалыгында Нияз абыйның улы Рияз, Рәвис абыйның уллары Риназ һәм Нәфис эшли. Рияз хуҗалыкка рәсми төстә 2012 елда армиядән кайткач урнаша. Ә рәсми булмаганы, үзе әйтмешли, балалар бакчасыннан ук.

– Кечкенәдән бирле рульдә инде мин. Әни кырга җибәрмәгән көннәрдә качып чыгып киткән чаклар да булды. Миңа: «Син тракторда тугансыңдыр», – дип әйтәләр иде. Эшемне бик яратам. Яратмасаң, эшләп тә булмый аны. Авылда яшьләр юк, эшләргә кеше аз. Минем үземә барысы да ошый. Хезмәт хакы яхшы, ай саен түләп баралар, яшәргә урын бар. Бабай, әти эзеннән китүем белән горурланам. Авылда калып, аларның фамилиясен, эшен дәвам иттерәсем килде. Кайда төяү, бушату, күтәрү – мин шунда. Аңа кадәр кырда эшләдем, – диде Рияз.

Риназ хуҗалыкта 2016 елдан бирле эшли.

– Китәсе килеп алган вакытлар да булгалады, ләкин күңел авылга тартты. Эшемне яратып эшлим. Сер түгел, күңел төшкән чаклар да, арып киткән көннәр дә була, тик эш белән алары да уза, – диде яшь механизатор.

Таңнар ничек ата?

«Таң» хуҗалыгы директоры Рафис Миңнеханов та әтиле-уллы Идрисовларны мактап телгә алды.

– Бу нәсел – батырып эшли торганнардан. Хуҗалык тоткалары булырдай мондый егетләр санаулы гына. Алар кебекләр, авылдан китеп, үз эшләрен булдырды инде. Нияз белән Рәвис үзләре дә, уллары да хуҗалыкны калдырып чыгып китмәде. Моның өчен аерым рәхмәт аларга, – диде ул.

Әлеге вакытта хуҗалыкның 1500 гектар сөрүлек җире, 2500 баш мөгезле эре терлеге бар, шуларның 800е – сыерлар. Уңышлары да җитәрлек. Тик әлегә сүзебез үзенән-үзе борчыган мәсьәләләргә барып ялганды.

– Такталачык авылы якларында шәхси хуҗалыкларда мал күп тоталар. Теләкәйдә алай ук түгел. Халыктан да 3,5 тонна тирәсе сөт җыябыз. Без сөт бәяләрен әллә ни төшермәдек. Бүгенгә кадәр 23 сумнан түләдем. Шуңа күрә әлегә малларны киметүчеләр юк, – диде хуҗалык җитәкчесе. – Ләкин көзгә таба ни буласын әйтеп булмый. Әлегә авыллардан узган елгы печәннәрне ташыйлар. Быел хуҗалыкның халыкка ярдәм итү мөмкинлеге юк. Үзебезне алып чыга алсак ярый әле, чөнки иген уңышына зур өметләр баглап булмый. Гектарыннан 15–20 центнер уңыш җыеп алсак, бик әйбәт булыр иде. Кабаттан чәчкәннәр дә әллә ни үсеп китә алмады. Сатарлык икмәк запасы юк. Киләсе елда да яшисе бар бит әле. Терлек санын арттыру түгел, киметү турында уйлыйбыз. Азык җиткереп булмас. Авыр ел булачак.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

Яшьләр белеп үссен

Өлкәннәр тормышы

Югары Осланда узган очрашуда бу сүз еш кабатланды. Татарстан ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасының еллык пленумы да яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирү темасына багышланган иде. Бу мәсьәлә хәзер бик әһәмиятле, дигән фикердә алар. Оешма рәисе Хәбир Иштирәков әйтүенчә, махсус хәрби операция барган вакытта үз илең турында күпме сөйләсәң дә, комачау итми.

– Төрле фикерләр ишетеп торабыз. Без – үз Ватанын, илен яратып үскән буын. Балаларыбыз да дөрес юлны сайласын иде, – диде ул җыелганнарга.

Утырышка республиканың барлык районнарындагы ветераннар советлары рәисләре килгән иде. Аларга район буйлап экскурсия дә оештырылды. Иннополис шәһәре бик гаҗәпләндергән үзләрен. «Йөртүчесез машиналарны, роботларны күргәнебез юк иде. Мондый әйберләрне телевизордан гына карый идек. Замана алга атлый. Республика тик ятмый», – ди Азнакай районының ветераннар советы рәисе Миргасыйм Кәримов.

Районның балалар-яшүсмерләр клубында кунаклар ветераннар иҗаты күргәзмәсен һәм «Безнең хәтер музее» экспозициясен карадылар. Музей берәүне дә битараф калдырмады. Аны Югары Ослан районының ветераннар советы рәисе, «Хәтер вөҗданы» җирле эзләү отряды җитәкчесе Римма Троицкая оештырган. Сүз уңаеннан, ул оныгы Дмитрий Данилов белән елына ике тапкыр Волгоград, Ленинград, Новгород, Орел өлкәләрендәге элеккеге сугыш урыннары буенча экспедицияләргә чыга.

– Бүген залда туган ягына махсус хәрби операциядән кыска вакытлы ялга кайткан кешеләр дә бар, – ди Римма Троицкая. – Ватанны саклаучыларга алгы сызыкта башлаган эшләрен ахырына җиткерүләрен һәм тизрәк җиңү белән кайтуларын телибез. Без күңел белән һәрвакыт сугышчыларыбыз янында. Фронтка алты тапкыр гуманитар ярдәм җибәрдек. Район халкына рәхмәт. Алар һәрдаим хәрбиләр өчен акча җыя, кирәк-яраклар туплаша. Мәрхәмәтле кешеләр ярдәме белән автомобильләр, махсус техникалар да якташларыбызга барып җитте.

Өлкәннәр ни өчен нәкъ менә Югары Ослан районына җыелды соң? Хәбир Иштирәков әйтүенчә, бу район – чын геройлар туган җир.

– Бөек Ватан сугышы елларында Югары Ослан районының 11 мең кешесе фронтка китә. Чагыштырып карагыз: бүген районда 17 мең кеше яши. Югарыосланлыларның яртысыннан артыгы сугыштан әйләнеп кайтмаган. Районда туган алты кеше Советлар Союзы Герое исемен йөрткән, тагын җидесе бу югары исемгә тәкъдим ителгән һәм башка орден-медальләр белән бүләкләнгән. Алар арасында данлыклы геройларның берсе 1942 елның июлендә фронтта легендар батырлык күрсәткән танкист Семен Коновалов була, – дип сөйләде Хәбир Иштирәков. – Ул Воронеж – Ворошиловград операциясен үткәрү вакытындагы сугышларның берсендә КВ-1 танк экипажы белән командалык итеп, дошманның 16 танкын юк итә. Дошман белән ялгызы сугыша. Аны үлгән дип уйлыйлар. Бәхеткә, Семен Коновалов исән кала һәм өенә кайта. Югары Осланның Ямбулат авылыннан килгән сугышчы турында дистәләгән китаплар язылган, популяр «Несокрушимые» нәфис фильмы төшерелгән. Менә шушы бер кеше мисалында гына да Ватанны ярату, ил өчен утка-суга керергә әзерлекне күрергә була. Без хәзерге балаларны да үз җиренең ватанпәрвәре итеп тәрбияләргә тиеш.

Хәбир Иштирәковны бик күп мәсьәләләр борчый. Ул район җитәкчеләренең үз өлкәннәренә җылы мөнәсәбәттә булуын тели. Шулай ук дәүләт җитәкчеләренә дә сүзе бар: өлкәннәргә бәйле проблемаларны хәл иткәндә, ветераннар советы рәисләренә дә мөрәҗәгать итсеннәр иде. «Авырткан урыннарны бездән башка берәү дә яхшырак белми», – ди ул.

Югары Ослан район башлыгы Марат Зыятдинов исә өлкәннәр белән аңлашып эшләүләрен әйтте.

– Һәр эштә өлкәннәр тәҗрибәсе кирәк. Нинди генә чара булмасын, алар ярдәмгә килә. Район ветераннары советы рәисе Римма Троицкая хакимият белән тыгыз элемтәдә тора. Без 12 ел бергә эшлибез. Нинди генә ярдәм кирәксә дә, кулдан килгәнне эшләргә тырышабыз, – ди ул.

Чыгыш ясаучыларның күбесе бертавыштан: «Балалар мәктәптә үк бу хакта белеп үсәргә тиеш», – диделәр. Казанның дары заводыннан килгән белгеч – хәзерге шартларда ничек эшләүләре хакында, Тукай районының ветераннар советы рәисе үзләрендә эшләп килүче «Гиндукуш» әфганчылар музее хакында сөйләде. Махсус хәрби операциядән кайткан ир-атларны халык аягүрә алкышлады. Район башлыгы исә өлкән сержант Владимир Дюсеевка Россия Президенты Указы белән бирелгән Батырлык орденын тапшырды.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

Әйтер сүзем бар иде

Күптән түгел «Ватаным Татарстан» газетасында «Безнең флот» дигән игъълан-мәкаләне укып, бик шатландым. Ничә еллар хуҗасыз булып, мескен хәлгә төшкән Елга порты торгызылачак икән.

Димәк, елга портының үзәк бинасы ишекләрен ачып, сәяхәтчеләрне кабул итәчәк. Ярым җимерек хәлгә килгән портның биналары төзекләндерелеп, күзләрне иркәләячәк. Тимер рәшәткәләр белән чолгап алынган яр буйлары да «тоткынлык»тан арыныр, дигән өмет тә бар.

Елга портыннан тимер юл вокзалына, күпергә кадәр сузылган дамбаның җимерек бөтен диварлары сүтелеп, матур, милли челтәрле чуен рәшәткәләр дә куелуы бик ихтимал.

Дамба буйлап сузылган, тәртипсез үскән агачлар да киселеп, узган гасырның 60–70 нче елларында шәһәр халкы язын-җәен ял иткән Идел яры да, бәлки, үзгәрер?

Хәзерге вакытта яр буе чүп-чарга батып ята. Яшьләр, җиңел машиналарга төялеп, дамбага килеп, ачык һавада учак ягып, шашлык кыздыралар. Кипкән үләннәргә, агачларга ут кабуы бик ихтимал. Дамбада ут чыкса, Иделдән искән җил аркасында тимер юл вокзалын, тепловозлар депосын ялкын чолгап алачак.

Шөкер, шәһәребез шатланырлык күп кенә үзгәрешләр кичерә. Башкаланың Бауман урамындагы матурлыкка туристлар сокланып йөри. Саратов шәһәреннән килгән туристлар белән танышырга насыйп булганы бар миңа. Һич онытасым юк: алар, соклануларын яшермичә: «Казань, оказывается, это совсем другой мир», – дип, миндә горурлык хисләре уяткан иде.

Туристларның берничәсе татар милләтеннән иде, ахры. «Нишләп Татарстанның башкаласындагы тарихи матур урам (элекке Проломная) Бауман исемен йөртә? – дип сорауларына ачык кына җавап биреп булмады.

Россиянең Өченче башкаласы дип саналган шәһәр үзәгендә татар милләтеннән ерак торган исем бер дә милләттәшләребезне, шәһәр халкын шатландырмый. Шушы үзәк урамга, чын милли исем бирүне оештырырга конкурс игълан ителеп, урам исеме үзгәрсә, горурланыр идек. Татарстанның Беренче Президенты, халкы өчен җан атып йөрүче Минтимер Шәрипович Шәймиев исемен мәңләгән кеше хуплар иде. Шәһәрнең «иң үзәк» урамы да исемен алыштырып, хәзер Кремль урамы дип атала. Свердлов урамы – Петербургка, Киров урамы Мәскәүгә үзгәрде. Куйбышев исемендәге мәйдан Тукаебыз исемен алырга лаеклы булды.

– Шулай уйламаганда-көтмәгәндә экскурсовод булып китүем Саратов кунакларына ошады. Алар тагын да кызыксынып, Бауман урамындагы җир астына төшә торган бетон корылмаларны күреп: «Нәрсә, әллә бу бомбоубежищемы?» – дип сорадылар. Шул корылма – катакомбаның тирән чокырында ике сәрхуш үз хаҗәтләрен үтәп маташалар иде. Оятымнан сүзсез калдым…

1990 елларда казылган һәм урам буенча сузылган «катакомба» бүгенгә кадәр туристларны гаҗәпләндерә. Мондый искитмәле корылма бездә генә бар. Димәк, без беренчеләрдән булып алда барабыз, метробызга өстәп «катакомба»быз да бар. Аны төзергә боерык биргән җитәкчеләргә һәм шәһәрнең баш архитекторына мең рәхмәт инде…

Казанга килгән туристларга Каюм Насыйри урамындагы «Иске Татар бистәсе»н күрсәтәләр. Мәрҗани исемендәге мәчеткә каршы торучы ярым җимерек бер катлы агач йортны күрсәтү инде чамадан артык… Шул мескен җимерек йортны яңартабыз дип буяп, тәрәзәләренә челтәр элгәннәр. Өй түбәсе кыйшаеп, тиздән җимерелеп төшәр дәрәҗәгә җиткән.

Шул уңайдан, туристлар Кабан «диңгезе»н дә күреп, Татарстан урамына чыксалар, юл аша 16 һәм 18 нче йортлар арасындагы җимерек, ташландык йортны күреп гаҗәпләнәләр. Инде 25 елдан да артык шушы җимерек йорт, Париж Коммунасы урамын гына түгел, Мәскәү, Татарстан урамнарын да «бизи»…

Шәһәр, район җитәкчеләре шуны күрмиләрме, әллә инде шундый кыйммәтле җирнең качып йөргән хуҗасын тапмыйлармы?

Казан шәһәре җитәкчеләренә тырышып халыкка хезмәт күрсәтүләре, киләсе буынга төзек матур йортлар, урамнар калдырасына өмет итеп, рәхмәтләремне җиткерәм. Шулай ук тәнкыйть сүзләрен үпкәләмичә кабул итсәләр, хөрмәтебез тагын да артыр иде.

Альберт ГАДЕЛШИН,
Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы

Җиләкле Чатыртау

Чатыртау җыеннары үтүгә, бу әкияти аланлыкларга кәрзиннәрен тоткан җиләкчеләр агыла башлый. Сәхрәдә шифалы яңгыр, җылы кояш астында пешкән мондый да татлы, авызында балдай эри торган җиләкләр беркайда юктыр. Шуңа да җиләкләрне дәва өчен җыярга махсус киләләр Чатыртауга. Дөя өркәчләрен хәтерләткән биеклекләр, түмгәкле аланнар, Пугачев йөргән эзләр каршы ала. Әле кайчан гына районның ветераннар советы рәисе Миргасыйм Кәримовка:

– Җиләк җыючылар ярышы үткәрик, кем өлгеррәк, кем остарак – шуны ачыкларбыз, – дип әйтүемә, ул тәкъдимне хуплап та алган иде.

Хәзер Чатыртауда җиләкләр пешүгә уздырылучы ярыш матур бәйрәмгә әйләнде. Быелгысы тагын да ямьлерәк – истәлекле булырга охшый, чөнки нәкъ шушы вакытта Миргасыйм Ильяс улының 80 яшьлек юбилее. Карабодай игүдәге хезмәтләре өчен СССР Министрлар Советы премиясен алган галим-агроном ул. Аның әле иң күп җиләк җыючыга шәхси призы да әзерләнә дип беләм. Җиләк кенәме? Мәгърур тавыбыз итәгендә шифалы үләннәр дә күп. Искиткеч табигать матурлыгына мөкиббән булган районыбызны ике дистә еллар җитәкләгән Әнвәр абый Баһаветдинов искә төшә. Үзенең «Волга»сына әрем җәеп йөри иде ул. Район газетабызда «Безнең яшел аптека» дигән даими рубриканы үзе башлап, кызыклы язмаларны да үзе яза иде. Аның дәвамчысы

vk.com

Әнәс Исхаков та туган җиребезнең бөтенлеген саклауда янып-көеп йөрде, районыбызның Кызыл китабына тикле чыгарды.

Ә минем Сәпәй авылы Чатыртауның нәкъ итәгендә – шуннан сихри күренеш ачыла. Бераз атлауга җиләкле аланнар. Мәшһүр Тукаебыз әйткәнчә, «күз ачып йомганчы җыярсың бер чиләк». Әле ул «Ватаным Татарстан» газетасы өчен дә аерым әһәмияткә ия: заманында «Социалистик Татарстан»ның үз хәбәрчесе, аннары баш мөхәррире урынбасары һәм Татарстан китап нәшрияты директоры булып эшләгән Гарәф Шәрәфетдинов яшьлегендә «Кызыл Байрак» колхозын җитәкләгән. Монда туган һәм яшәгән Дамир Асылов озак еллар «ВТ»ның нефть төбәгендәге хәбәрчесе иде. Йөзьяшәр газетабызга караган менә шундый матур сәхифәләр дә бар җиләкле Чатыртау төбәгебездә!

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай районы

Гарифҗаннар күбрәк кирәк!

Син – белүче милләтеңнең серләрен
Һәм дә аның бик авырткан җирләрен.
Кайтарырга милләтенә дәүләтен,
Көтә тарих Гарифҗандай ирләрен!

Нәҗибә САФИНА

2003 елның көзендә туган авылым Чапшарга әтигә бәрәңге алышырга кайттым. Эшләрне бетергәч, кичке тугызларда Казанга китәргә дип өйдән чыктым. Сентябрь ае, салкынча, җәяүләп 7 километр ераклыктагы Балтачка таба атлый башладым. Ай яктысы да бар, каршыга бервакыт кешеләр килә башлады. Кешеләр дигәнем агачлар булып чыкты. Туңып, арып Балтачка килеп җиттем дә Гарифҗан абыйларның өй ишеген шакыдым. Инде төнге сәгать 11 булган икән, Гарифҗан абый мине күреп аптырап китте. Хәлемне аңлап, өйләренә чакырды. Гарифҗан абыйның хатыны Асия апа – бик ачык, кунакчыл кеше. Алар мине табынга утыртып ашаттылар, эчерттеләр, хәлләремне сорадылар, тынычландырдылар, күңелемне күтәрделәр. Аннары без Гарифҗан абый белән аның эш бүлмәсенә кереп сөйләшеп утырдык, киләчәккә иҗат планнары кордык. Икенче көнне алар мине якын туганнарыдай Казанга озатып җибәрделәр.

2011 елда да, Балтачка эш белән кайткач, Гарифҗан абыйларда туктарга туры килде. Мунча кереп, остазым белән рәхәтләнеп аралаштым. Гарифҗан абый белән сөйләшү – зур бәхет, белмәгән нәрсәсе юк. Татар җанлы, кыю фикерле акыл иясе ул. Хәзер дә мин аның белән телефоннан шалтыратышып, киңәшләшеп яшим.

Шагыйрь, язучы, галим, дәүләт эшлеклесе дустым Гарифҗан абый Мөхәммәтшинны якыннан белүем белән горурланам! Быел аксакал әдибебезгә 82 яшь тула. Киләчәктә дә безне шатландырып яшәргә язсын сиңа, бөек дустым!

Зөлфәт ХӘЙРУЛЛИН.
Казан

Яшьлек хатирәләре

БЫРГЫ КЫЧКЫРТАСЫ КИЛЕП ТОРА

Пионер елларымны әледән-әле сагынам. Пионерга кергән көнне кызыл галстугымны җилфердәтеп, күкрәк киереп өйгә кайтканым да онытылмый. Дөрес, галстукның өйдә онытылып калган вакытлары да булды, бәйләргә өйрәнеп җәфаланган да хәтердә. Бала-чагага өйдә үтүк кабызырга рөхсәт ителми, шулай да җаен табарга тырышабыз: галстукны йомарланмасын өчен, суда чылатып, матрас астына җәеп куя идек, шунда еш кына онытылып та калгалады.

Пионерия көнендә мәктәптә линейка уза, аннары барабан кагып, быргы кычкыртып, урам әйләнәбез. Мәктәп янәшәсендә Таштау дип йөртелүче биек тау бар иде. Шунда менеп, авылга карап сокланабыз, уеннар уйныйбыз. Бик күңелле мизгелләр. Әле дә барабан кагасы, быргы кычкыртасы килеп тора.

Җәвит ШАКИРОВ.
Казан

БАЛЫКЛАР ИСКӘ ТӨШӘ

Җәй айлары, әти белән балык тотып йөргән чаклар искә төшә. Дөресен генә әйткәндә, балык тоту ташу вакытларында ук башлана иде. Минем сеңелнең, әти белән балыкка баргач, ташу суында агып та киткәне булды әле, әти үзе суга сикереп көчкә алып чыккан. Язын балыкка күп йөрдек. Мәктәптән кайтып, ашап-эчеп алабыз да әти алып китә. Ятьмә белән тота иде ул балыкны. Әле ташу суы китеп бетмәгән, су хәйран куәтле вә көчле ага. Озын колга башына беркетелгән ятьмә белән әти сөзеп чыгара, ятьмәдәге балыкны җиргә селкеп төшерә, шуларны мин чиләккә чүплим. Аларны чүпләп бетергәнче әти инде икенче ятьмәне сөзеп чыгарган була. Көчкә чүпләп өлгерә идем. Иң күбе ташбаш белән гөли балыклары керә иде. Көн саен дип әйтерлек ике табалык тотып кайта идек. Барысын да әти үзе эшли иде: чистарта, кыздыра, өстәлгә китереп утырта.

Балачактагы балык тәме хәзер юк инде. Әле беркөнне кибеттән шактый кыйммәт бәягә берничә балык алып кайтып пешердек. Ни тәме, ни туклыклылыгы… Әти белән яз көнендә тоткан кебекләр бүтән булмас та инде ул. Их, һич югы бер тапкыр гына булса да ашап карыйсы иде шундый тәмле балыкларны!..

Фәрит ВАФИН.
Арча районы

САГЫНУ

Яшьлек хисләремне шигырь юлларына төреп җиткерергә булдым әле.

Сандугачлар сайрый урманнарда,
Ниләр сөйли алар таңнарда?
Тәгәрәшеп бергә үскән идек,
Язмышлар таратты кайларга?
Торган җирләрем дә бик матур –
Урманнары, кыры, даласы.
Берни күренми күзләремә,
Сагындыра авылым һавасы.
Авылымның кычытканнары да,
Әрем исләре дә ягымлы.
Оныта алмыйм һич тә, сагынам
Шунда үткән бала чагымны.
И авылым, син дә шиңәсең бит,
Чәчәкләрен койган гөл кебек.
Хуҗалары киткән тәрәзләрдән
Тормый хәзер якты бөркелеп.

Флера ФӘЙЗЕТДИНОВА.
Спас районы Ямбакты авылы

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Өлкәннәргә дә, яшьләргә дә мөрәҗәгать итүебез: нәкъ менә балачактагы хатирәләрне күңелегездә яңартып, «Һич онытасым юк» сәхифәсенә язмалар юллагыз әле.
Үзегезгә үткәнгә кайтып килү булса, башкаларга да соклану, йә булмаса гыйбрәт алу булыр.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры **Җәббаров** Марат Азат улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«Татарстан Республикасы «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесенең архитектура, шәһәр һәм торак төзелешен үстерү идарәсе хезмәткәрләре: җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга өлеш кертүе һәм торак сәясәтен үстерүдәге казанышлары өчен торак төзелешен үстерү бүлеге башлыгы **Жукова** Фидания Җиһангәрәй кызы, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга өлеш кертүе һәм шәһәр төзелеше өлкәсендәге казанышлары өчен генераль план һәм территорияләрне үстерү бүлеге баш белгече **Юрина** Инга Геннадьевна «**Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Югары дәрәҗәдәге һөнәри осталыгы, республиканың дәүләт хакимияте органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе баш киңәшчесе **Ксенофонтов** Марсель Николаевич «**Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Шагыйрь, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» җәмәгать оешмасы (Иҗат берлеге) әгъзасы, «ТАТМЕДИА» акционер җәмгыятенең «Казан» – «Казань» журналы редакциясе» филиалы җитәкчесе – баш мөхәррире **Әпсәләмова** Альбина Булат кызына; композитор, продюсер, «Россия Федерациясе Кинематографиячеләр берлеге» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасы төбәк бүлекчәсе әгъзасы **Әхмәтшин** Марат Үзбәк улына, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Дизайн һәм пространство сәнгате институтының дизайн һәм милли сәнгатьләр кафедрасы доценты **Яо** Михаил Константиновичка **«Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Шәхси эшкуар Төхвәтуллин Ришат Айрат улы балет артисты, «Төмәнәк» татар иҗтимагый тарихи-мәдәни үзәге» җирле иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Бәдертдинов** Илгиз Әгъләм улына, «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе оркестры артисты **Закирова** Динә Ильяс кызына, «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе оркестры артисты **Сираев** Рөстәм Ришат улына, «В.И. Качалов исемендәге Казан академия рус зур драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе драма артисты **Козлова** Алёна Анатольевнага **«Татарстан Республикасының атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

Спорт

Сынатмасын машинаң!

ДАНЛЫКЛЫ РАЛЛИ-ЯРЫШ КАБАТ ТАТАРСТАННАН СТАРТ АЛА

kamazmaster.ru

Россиянең 13 төбәге, өч сәгать поясы, тугыз көнлек юл. Татарстанда «Ефәк юлы – 2023» узышына әзерлек дәвам итә. Данлыклы ралли 6 июльдә Казанның Меңьеллык мәйданыннан кузгалып китәчәк. Аннан соң машиналар өчен трассада ярыш башлана.

Юкка түгел

Старт мәйданы итеп Татарстан башкаласын сайлаулары юкка түгел. Ралли инде Казанга өченче мәртәбә (2009, 2016 еллар) кунак булып килә. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның да халыкара класслы спорт мастеры булуын онытмыйк.

– Саннарга карыйсың да ышанасы килми: 14 ел элек без беренче тапкыр Казанда «Ефәк юлы»н башлап җибәргәнбез! Быел безнең яңадан әйләнеп кайтуыбыз. 4 июльдә Шәле авылы тирәсендә ярышларда катнашучылар өчен тест-узыш узачак. Чараның тантаналы ачылышы көннәрендә Казанның кайбер урамнарында хәрәкәт чикләнәчәк, – диде Татарстанның спорт министры Владимир Леонов.

Ярышта катнашучыларны 5241,27 чакрымлык маршрут көтә. Юлның 2277,54 чакрымы тизлекле махсус участокларга туры киләчәк. Татарстандагы махсус участокның озынлыгы 500 чакрымнан артык юлны тәшкил итәчәк. Ул Лаешның Державино авылыннан башланып, Мамадыш районының Катмыш авылы янында төгәлләнәчәк. «Ефәк юлы»н оештыручыларның берсе Азат Абусев әйтүенчә, бу участок катнашучыларга ярышларга ияләшеп китү өчен бер дигән булачак. Тик җиңел юл түгел, аның да үз көйсезлекләре бар икән.

– Ярышның беренче махсус участогында катнашучыларга чокырлы, грунт юлларны үтәргә туры киләчәк. Аның каравы юлның дистанциясе озын түгел, бу пилотларга да, штурманнарга да ярышка ияләшеп китү өчен яхшы булачак. Әмма юл һава торышына бәйле. Аз гына яңгыр яуса да, юл тайгак булачак, тизлекне киметергә, катнашучыларга барлык осталыкларын күрсәтергә туры киләчәк, – дип кисәтә ул.

Азат Абусев сүзләренчә, экипаж юлны алдан белми. Аларга навигатор кулланырга рөхсәт ителми. Катнашучыларның кулында – юл картасы гына.

– Катнашучыларны үзенчәлекле ярыш көтә дип саныйм. Төрле төбәкләр, төрле юллар, төрле һава торышы һәм сынаулар... «Ефәк юлы» – иң җитди һәм катлаулы ралли-ярышларның берсе, – диде ул.

«Ефәк юлы» составы

Ралли-ярышка биш «КамАЗ» чыгачак. Шунысы да үзенчәлекле: экипажның берсе күпмилләтле булачак.

Ярышта катнашучылар:

Эдуард Николаев – Евгений Яковлев – Богдан Кәримов;
Андрей Каргинов – Иван Мальков – Вадим Әхмәтов;
Сергей Куприянов – Дмитрий Никитин – Иван Татаринов;
Хоу Хуннин – Шен Синь – Сергей Кренёв.

– «Ефәк юлы» шәхсән минем өчен үзенчәлекле булыр төсле, чөнки исемлектә моңа кадәр ярышта катнашмаган яңа төбәкләр бар. Старт, гадәттәгечә, Казаннан. Уфага таба юл алачакбыз, аннан Магнитогорск, Самара, Оренбург яклары көтә. Моңа кадәр бу төбәкләр ярышны кабул итми иде. Теләсә нәрсәгә: яңгырга да, башкасына да әзер булырга, барлык шартларны да исәпкә алырга кирәк, – ди бу җәһәттән Дмитрий Сотников.

Раллида барлыгы 98 экипаж-катнашучы стартка чыгачак дип ниятләнә. Т5 йөк зачетында дүрт командадан 12 автомобиль катнашу өчен гариза биргән.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Ралли программасы

5–6 июль – техник һәм административ тикшерү чаралары
6 июль – старт (Казан)
6–15 июль – ярыш этаплары (төрле шәһәрләр аша уза)
15 июль – финиш (Мәскәү)

СЕБЕРДӘН АЛЫП ЛЕНИНГРАДКА КАДӘР

Узган елларда милли бәйрәмебез – Сабан туе берьюлы берничә төбәктә гөрләп узды. Йөзәрләгән мең кешене берләштергән бу бәйрәмнәр нилләр белән истә калыр?

Кемерово

Бу төбәктә быел ике Сабан туен берләштереп бәйрәм иттеләр. 1 июльдә Кемеровода XXIII федераль Сабан туе һәм III халыкара шахтерлар Сабан туе узды. Киң колачлы бу бәйрәмдә җәмгысы 10 мең кеше катнашкан, дип хәбәр иттеләр. Кузбасста яшәүче милләттәшләребезне бәйрәм белән котларга Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та барды. Сүз уңаеннан, хәзерге вакытта анда 22 мең татар яши.

– Төрле милләт һәм дин вәкилләре татулыкта яшәгән искиткеч шәһәрдә булуыма чын күңелдән шатмын. Монда аңлашылмаучанлыкларга урын юк. Хәтта губернаторыгыз татар кешесенә миңа караганда күбрәк охшаган, – дип шаяртты ул, Кузбасс губернаторы Сергей Цивилевка күрсәтеп. – Сез – бик ачык күңелле һәм игелекле халык. Барчагызны да бәйрәм белән!

Аның сүзләрен губернатор да куәтләде.

– Без барлык милләт вәкилләре белән татулыкта яшәргә, һәм бу кыйммәтләрне киләчәк буынга тапшырырга телибез. Сабан туе – хезмәт, мәхәббәт һәм дуслык бәйрәме ул, – диде Сергей Цивилев, Федераль Сабан туеның символы – «Тулпар ат»ны Марий Эл Республикасы Хөкүмәте Рәисе урынбасары Михаил Васютинга тапшырып. Ягъни 2024 елда бәйрәм Йошкар-Ола шәһәрендә узачак.

Татарстан Рәисе белән Кемерово өлкәсе губернаторы бәйрәм мәйданын да урады. Традиция буенча, монда татар һәм Кузбасс ишегаллары әзерләнгән иде. Татарларның көнкүрешен, шөгыльләрен күрсәтә торган ишегалдын Лениногорскидан ук килеп ясаганнар. Соңыннан агачтан ясалган бу корылмаларны Кемерово өлкәсенең татар милли-мәдәни автономиясенә бүләк итеп калдырдылар.

tatarstan.ru

«Татар-информ»

Федераль Сабан туенда ике рекорд куелды. Кузбасс пешекчеләре, Рөстәм Миңнеханов һәм Сергей Цивилев ярдәме белән, 200 литр шахтерларча өйрә әзерләде. Икенче рекордны спортчылар куйды: барлыгы 100 кеше 30 минут дәвамында бертуктаусыз гер күтәрде. Бу рекордларның икесе дә Россиянең Рекордлар китабына кертеләчәк.

Һәр Сабан туендагы кебек, Кузбасста да күп тамашачының игътибары көрәш бара торган келәмдә иде. «Федераль батыр» исеменә Кузбасс, Татарстан, Новосибирск өлкәсе, Алтай һәм Красноярск төбәкләреннән килгән 150ләп спортчы бил алышты. Рөстәм Миңнехановның махсус бүләге – «Лада Гранта» машинасын, 57 мең сум акча һәм тәкәне тумышы белән Зәй районыннан булган Радик Сәлахов Татарстанга алып кайтып китте.

Татарстан Рәисе, Кемеровога эш сәфәре кысасында, Кузбасс башкаласының Җәмигъ мәчетендә булды һәм Кемерово өлкәсе мөфтие, татар милли-мәдәни автономиясенең төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Таһир хәзрәт Бикчәнтәев белән очрашты. Рөстәм Миңнехановка Җәмигъ мәчете янында «Туган йорт» татар милли-мәдәни үзәген ачу планнары турында сөйләделәр. Анда Кузбасс татарлары, төрле чаралар үткәреп, килгән кунакларны үзләренең мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре белән таныштыра алачак. Моннан тыш, Рөстәм Миңнеханов Томь елгасының яңа яр буен карады, Азатлык алып килгән сугышчы мемориалына чәчәкләр салды, Кемероводагы Президент кадет училищесын һәм «Защитники Отечества» дәүләт фондының төбәк филиалында булды.

tatarstan.ru

Киров өлкәсе

2 июльдә кыр бәйрәме Киров өлкәсендә гөрләде. Малмыж районының Калинино авылында узган өлкә Сабан туенда Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

– Безнең өчен өлкә Сабан туенда катнашу – зур хөрмәт. Сабан туенда без язгы кыр эшләренең тәмамлануын бәйрәм итәбез. Һәм, әлбәттә, илебез катлаулы чор кичергәндә, без, нинди милләт һәм нинди дин вәкиле булуга карамастан, бердәм булуыбызны күрсәтәбез, – диде Татарстан Рәисе, Киров өлкәсе губернаторы Александр Соколовка, аның командасына һәм бәйрәмне оештыруда катнашкан һәр кешегә рәхмәтен белдереп.

Александр Соколов исә Татарстан белән Киров өлкәсе арасындагы хезмәттәшлекнең елдан-ел ныгуын әйтте.

– Бүген кунакчыл Киров җирендә гаҗәеп матур Сабан туе бәйрәмен билгеләп үтәбез. Бу бәйрәм язгы-җәйге кыр эшләренең тәмамлануын аңлата, димәк, хезмәт кешеләрен, төрле дин һәм милләт вәкилләрен берләштерә, – диде ул. – Татарстан Республикасы белән икътисад, мәдәният, транспорт һәм төзелеш өлкәсендәге хезмәттәшлек ике төбәк үсеше өчен дә бик файдалы. Ул киләчәктә тагын да киңрәк колач җәяр дип ышанам.

Сабан туе мәйданындагы татар ишегалдын Балтач районы әзерләгән иде. Якында гына кунаклар махсус остаханәдә татар халык ашлары әзерләп мәш килде. Ә Киров өлкәсе әзерләгән ишегалдында бу төбәктә яшәүче татарларның мәдәнияте белән таныштырдылар. Сүз уңаеннан, 2025 елда шушы ук җирлектә бөтенроссия авыл Сабан туе уздырырга ниятлиләр.

Билгеле, бәйрәм ат чабышы, көрәш һәм башка милли уеннарсыз узмады. Милли көрәштә исә монда да баш батыр исеменә Радик Сәлахов лаек булды. Шулай итеп ул Киров өлкәсеннән унынчы машинасына утырып кайтып китте.

Күңел ачу гына түгел. Эш сәфәре кысасында, Рөстәм Миңнеханов һәм Александр Соколов Киров өлкәсе белән Татарстан арасындагы чикләрне билгеләү турында килешүгә кул куйды һәм Сәүдә-икътисадый, фәнни-техник һәм социаль-мәдәни хезмәттәшлек турында килешүне гамәлгә ашыру буенча 2023–2027 елларга чаралар планын раслады. Моннан тыш, Рөстәм Миңнеханов Малмыж районындагы «Приор» җитештерүен карады. Предприятие җитәкчесе Рәшит Хәлиуллин Татарстан аграрийлары, аерым алганда, Теләче һәм Алексеевск районнары фермерлары белән хезмәттәшлек турында сөйләде.

Мәскәү

Узган елларда Сабан туен Россия мәркәзе – Мәскәүдә дә бәйрәм иттеләр. Әле ничек кенә! Шәһәр күләмендә уздырылган бәйрәмдә барлыгы 200 меңләп кеше катнашкан. «Коломенское» музей-тыюлыгында узган Сабан туен оештырырга Чаллыдан һәм Башкортстаннан килеп ярдәм иткәннәр.

Мәскәүдә яшәүче милләттәшләребезне Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да котлады.

– Мәскәү Сабан туе һәрвакыт үзенчәлекле була, чөнки монда татар һәм башкорт спортчыларының, үзешчән сәнгать вәкилләренең осталыкларын күрергә, иске танышларны, дусларны очратырга була. Гомумән, Сабан туе – борынгы заманнардан ук зур миссиягә ия бәйрәм. Мондый бәйрәмнәр халыклар арасында дустанә мөнәсәбәтләр булдырырга, төбәкләр һәм, гомумән, илкүләм татулыкка ирешергә ярдәм итә, – диде ул.

Элек-электән Сабан туенда спорт уеннарына аерым игътибар бирелә. Бу хакта Россиянең спорт министры Олег Матыцин да әйтте. Илдәге халыкларны берләштереп торучы традицияләрне саклаулары өчен Татарстан һәм Башкортстан республикаларына рәхмәтен дә җиткерде ул.

Башкалада узган Сабан туенең иң истәлекле мизгелләре Мәскәү елгасында узды, дисәк, ялгыш булмас. Монда ишкәкле спорт төрләренең берсе – регата буенча ярышлар узды. Ә мәйдандагы келәмдә Россия, Бангладеш, Казахстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Беларусь һәм башка илләрдән килгән егетләр көрәш буенча Дөнья Кубогы финалында бил алышты.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Дөнья Кубогы җиңүчеләре

russiakoresh.ru

60 килога кадәрге авырлыкта
Рөстәм Фәтхуллин (Россия)
65 килога кадәрге авырлыкта
Марсель Сөләйманов (Россия)
70 килога кадәрге авырлыкта
Эмиль Җиһаншин (Россия)
75 килога кадәрге авырлыкта
Мөнир Галләмов (Россия)
80 килога кадәрге авырлыкта
Мурад Гайдаров (Беларусь)
85 килога кадәрге авырлыкта
Кәрим Рузметов (Россия)
90 килога кадәрге авырлыкта
Ринас Садаров (Россия)
100 килога кадәрге авырлыкта
Илдар Моратов (Россия)
130 килога кадәрге авырлыкта
Раил Заһретдинов (Россия)
130 килодан авырраклар арасында
Сергей Павлик (Россия)

elabuga-rt.ru

Ленинград өлкәсе

Елдагыча, төньяк башкала татарлары Сабан туен Санкт-Петербург янындагы Энколово авылында бәйрәм итте. Сүз уңаеннан, кыр бәйрәмен бу җирлектә 1956 елдан ук билгеләп үтәләр. Тагын бер традиция буенча, быел да Ленинград өлкәсендә яшәүчеләрне күңел ачтыруга Алабуга районы җаваплы иде. «Ленинград төбәгендә яшәүчеләрне Татарстан мәдәнияте белән таныштыру мөмкинлеге биргәннәре өчен зур рәхмәтебезне белдерәбез», – дип язган үзенең «Телеграм»дагы каналында Алабуга районы башлыгы Рөстәм Нуриев.

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5091 данә
Гомуми тираж – 14042 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 293

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.

График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+